ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 06 » мая 2022 ел** **№ 14**

«2022-2024 елларга «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының « Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Чараларны башкаручыларга «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:\pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

**РАСЛАНДЫ**
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның «06» маенда 14 номерлы карары белән

**«2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы**

Гомуми нигезләмәләр

Программаның төп максаты Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү һәм шул нигездә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, халыкны эш белән тәэмин итү, җитештерү, хезмәт һәм интеллектуаль потенциалны үстерү.

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль программа исеме | «2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнар; «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| 3. Муниципаль программаның муниципаль заказчысы | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. Муниципаль программаның төп максаты | - кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы мохит тудыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлыкның гамәлдәге субъектларын булдыруга һәм саклауга ярдәм итү;<br><br>- базарны җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре белән баету;<br><br>- авыл җирлегендә яшәүче халыкны эш |

| | |
|---|---|
| | белән тәэмин итү. |
| 5. Муниципаль программаның төп бурычлары | Барлык дәрәҗәләрдә бизнес һәм хакимиятнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының (алга таба - субъектлар) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның (алга таба -оешма) үзара хезмәттәшлеге рәвешләрен һәм механизмнарын үстерү һәм камилләштерү;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсешен мониторинглау;<br><br>-кече һәм урта эшкуарлык турында уңай иҗтимагый фикер тудыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатуда ярдәм күрсәтү. |
| 6. Муниципаль программаның төп чараларын үтәүчеләр | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 7. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| 8. Муниципаль программа максатларына ирешү индикаторлары | - кече эшкуарлык субъектлары саны арту;<br><br>- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр саны арту;<br><br>- җитештерү күләмнәре үсү, продукция сату базары киңәю;<br><br>- җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләре киңәю. |
| 9. Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген агымдагы финанслау. |

1 нче бүлек.

## МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАРЫН ТАСВИРЛАУ

Кече эшкуарлык - икътисадның сәяси тотрыклылык, иҗтимагый үсеш, товарларның яңа төрләрен үзләштерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү өчен принципиаль әһәмияткә ия өстенлекле секторы. 2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә 392 кече һәм урта эшкуарлык субъекты эшчәнлек алып бара.

2 нче бүлек.

## МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОГЫ

Программаны гамәлгә ашыру срогы 2022 елдан 2024 елга кадәр

## 3 нче бүлек.
## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАСВИРЛАУ

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Чараларны башкаручылар | Җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 ел | 2 ел | 3 ел | Барлыгы |
| Муниципаль программаның максаты | | | | | | | |
| 1.1.Төп чаралар:<br><br>- җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сату базарын киңәйтү максатларында күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашуга җәлеп итү; | | 2022-2024 еллар | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |
| 1.2.Төп чаралар:<br><br>- Дәүләт ярдәмен алу мәсьәләләре буенча җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен консультацияләр оештыру | | 2022-2024 еллар | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |

## 4 бүлек.
## МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫНЫҢ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | 2021 ел үткәне | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның икенче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның өченче елы |
|---|---|---|---|---|---|
| - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны | Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән | 8 | 9 | 9 | 9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| арту; | кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны | | | | |
| - өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече һәм урта бизнеста эшләүчеләр саны арту; | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан бирелгән эш урыннары саны | 8 | 9 | 9 | 9 |
| - җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләре киңәю. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары җитештергән товарларның төрләре саны | 12 | 12 | 12 | 12 |

## 6 бүлек.
## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

| Финанслау чыганаклары | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | программаны гамәлгә ашыруның 1 елы | программаны гамәлгә ашыруның 2 елы | программаны гамәлгә ашыруның 3 елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен барлыгы |
| Җирле бюджет | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |

Программаның чараларын финанслау җирлек бюджеты исәбеннән башкарыла.

Бюджет акчалары күләме фараз характерында һәм тиешле бюджет проектын төзегәндә һәм караганда ел саен билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелергә тиеш.